**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Иске Маврин авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 9** **24.12.2025**

**«Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 104 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1.2018 елның 24 апрелендәге 104 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының «Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» карарына (28.05.2018 ел № 107, 26.11.2018 ел №134, 10.12.2018 ел № 136, 22.09.2020 ел № 8, 29.12.2021 ел №51, 30.09.2022 ел №77, 06.12.2022 ел №81, 28.02.2023 ел №97, 24.06.2024 ел №132, 10.12.2024 ел №146, 12.05.2025 ел №162 Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә:

2.2 пунктта «15 389 сум» сүзен «16 928 сум» сүзе белән алыштырырга;

2.14 пунктта «15 389 сум» сүзен «16 928 сум» сүзе белән алыштырырга;

1.2. Әлеге карар белән расланган «Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иске Маврин авыл җирлеге башлыгына акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 23 201 |

2. Карарны Иске Маврин авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Иске Маврин авыл җирлеге башлыгы,** **Р.Г. Нургалеев**
**Совет Рәисе**